ГЛАВА РАНГАЗАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ РАНГАЗАР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 ел 14 ноябрь № 6

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Балтамак авылы гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Рангазар авылы гражданнары җыенын Балтамак авылында 2022 елның 22 ноябренә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, ялгыз өлкән кешеләр, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Рангазар авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2023 елда үзара салымны 8000 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

- Балтамак авылы зираты территориясен койма белән әйләндерү өчен материаллар сатып алу;
- Балтамак авылы зиратына ритуаль кирәк-яраклар саклау будкасы төзү өчен материаллар сатып алу һәм эшләр өчен түләү;
- Балтамак авылларында кышын җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту.

ӘЙЕ ЮК

3. Гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны Рангазар авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

4. Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Рангазар авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Рангазар авыл җирлеге башлыгы: А.Р.Шарипова.